КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 апрель г.Казань № 427

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коллегиясе әгъзалары санын һәм составын раслау турында» 2022 ел, 17 март, 245 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коллегиясе әгъзалары санын һәм составын раслау турында» 2022 ел, 17 март, 245 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 9 апрель, 209 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Р.В.Гайнетдиновны чыгарырга;

коллегия составына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы Олег Рәшит улы Насыртдиновны кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин